ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.06.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1272**

Зеленодольск шәһәр пляжында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131 – ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары нигезендә, Идел елгасыннан шәһәр пляжы акваториясе пробаларының микробиологик күрсәткечләр буенча «Җир өсте суларын саклауга карата гигиеник таләпләр» СанПиН 2.1.5.980-00 таләпләренә туры килмәвен исәпкә алып, бәхетсезлек очракларын, кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Җир өсте суларын саклауга карата гигиеник таләпләр» СанПиН 2.1.5.980-00 таләпләренә туры килә торган су пробалары алганчы Зеленодольск шәһәренең шәһәр пляжында коенуны тыярга.
2. «Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе А.О. Антонова коенуны тыю турында кыска вакыт эчендә кисәтү аншлагларын урнаштыру эшен оештырырга.
3. «Зеленодольск муниципаль районының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр идарәсе» МБУ Зеленодольск районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге, «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча кече суднолар дәүләт инспекциясе үзәге» федераль казна учреждениесенең Зеленодольск инспекторлык бүлеге, «ТР ОСВОД» Зеленодольск бүлеге белән берлектә Зеленодольск шәһәре халкы һәм кунаклары тарафыннан коенуны тыю турындагы таләпләрнең үтәлешен тикшерү максатында су объектларында патрульлек, рейдлар оештырырга
4. Балаларны савыктыру лагерьлары, муниципаль белем бирү учреждениеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре директорларына тәрбияләнүчеләр белән су янында ял оештырганда иминлекне тәэмин итү мәсьәләләре буенча дәресләр – инструктажлар үткәрергә, әлеге карарны җиткерергә.
5. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге

башлыгына халыкка сулыкларда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү һәм Зеленодольск шәһәр пляжында коенуны тыю мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны «Зеленодольская правда», «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга, Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Карар имзаланган көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников